ГЛАВА КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

“8” ноябрь 2019 ел. № 6

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Катмыш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Катмыш авылы, Ленин урамы , 85 нче йорт адресы буенча урнашкан Катмыш авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 23 ноябрендә 12.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыщ авыл җирлегенең Катмыш авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Катмыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Катмыш авылы торак пуктында Ленин урамына юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);

-Катмыш авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Катмыш авылы торак пунктында “Урам чишмә” сен төзекләндерү (материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);

- Катмыш авылы торак пунктында елга янында янгын техникасы белән су алу өчен пирс булдыру ( сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча түләү);
- Катмыш торак пунктында энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитетына Катмыш авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габидуллин